Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Сәрән авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

15 ноябрь 2022 ел №15

Әлмәт муниципаль районы Сәрән
авылы башкарма комитетының кайбер
карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында»2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары нигезендә

Сәрән авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Сәрән авылы башкарма комитетының кайбер карарларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2022 елның 25 июлендәге 9 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 3.3.2.1 пунктындагы «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү органы (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер соратып алу формасындагы кырларны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Соратып алу электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырлары бердәм порталы белән ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон рәвештә хәбәр итү аша җиткерелә.»;

1.2. 2022 елның 6 апрелендәге 4 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 3.3.2.1 пунктындагы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (Әлмәт муниципаль районы Сәрән авылы башкарма комитетының 2022 елның 25 июлендәге 8 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер соратып алу формасындагы кырларны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Соратып алу электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырлары бердәм порталы белән ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон рәвештә хәбәр итү аша җиткерелә.»;

2. Әлеге карарны Чуаш Сәрәне авылы, Үзәк урам, 34б йорты; Рус Сәрәне авылы, Үзәк урам, 15а йорты; Кителга авылы, Совет урамы, 8а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

(PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сәрән авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.А.Севастьянов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СИРЕНЬКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р.06-1372/12
СИРЕНЬКИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1644036223
КПП 164401001
ОГРН 1061644002529
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «СИРЕНЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ